**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ЛАИШЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

Чернышевского ул., д.23, г.Лаишево
422610

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЛАЕШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

Чернышевский урамы, 23нче йорт
Лаеш ш. 422610

Тел: 8-(84378) -2-52-28 Факс: 8-(84378) -2-54-34
e-mail: Ispolkom.Laishevo@tatar.ru

---

**2021елның 29 гыйнвары** **109 номер**

# КАРАР

**«Мәктәпкәчә белем бирү программасын гамәлгә ашыручы мәгариф оешмаларына йөрүче балаларга социаль ярдәм чараларын күрсәтү турында» 2013 елның 26 сентябрендәге 2116 номерлы Лаеш муниципаль районы башкарма комитеты карарына үзгәрешләр кертү хакында**

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль закон, «Ана (гаилә) капиталы чаралары белән бәйле мәсьәләләр буенча РФнең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2020елның 01 мартындагы 35-ФЗ номерлы Федераль законы нигезендә , ТР Лаеш муниципаль районы башкарма комитеты карар бирә**:**

1. Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Башкарма комитетының «Белем бирү программасын гамәлгә ашыручы мәгариф оешмаларына йөрүче балалары булган гражданнарга социаль ярдәм чаралары күрсәтү турында» 2013 елның 26 сентябрендәге 2116 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2 өлешнең 2.1 пунктына «Компенсация билгеләү һәм түләү тәртибе» пунктчасын түбәндәге эчтәлекле «l» пунктчасы өстәргә:

«l) -компенсация бирү өчен мөрәҗәгать итүченең салымнар, җыемнар, иминият кертемнәре, пенялар, штрафлар, салымнар һәм җыемнар турындагы РФ законнары нигезендә түләнергә тиешле процентлар түләү буенча үтәлмәгән бурычы булмау шарт булып тора»;

2. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча һәм Интернет-телекоммуникация челтәренд Лаеш муниципаль районының рәсми сайтында http://laishevo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең беренче урынбасары А.Г. Карсаловка йөкләргә.

**Җитәкче** **А.А.Новиков**